ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 413-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Тыгин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» 413-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 20 апреле
№ 1946-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 33 статьясындагы $3^4$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), «түләү» сүзен «түләү алу, мондый юллардан, мондый участоклардан ташламалы йөрүне яисә мондый юллардан, мондый участоклардан түләмичә генә йөрүне рөхсәт итү тәртибе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 40 һәм 41 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 28 февралендәге 47-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы, җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә региональ яисә муниципальара әһәмиятле, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан ташламалы йөрүне яисә түләмичә генә йөрүне рөхсәт итү тәртибен раслау каралган.

Закон проекты белән югарыда искә алынган Татарстан Республикасы Законының гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан йөргән өчен түләү алу тәртибен регламентлаштыра торган 33 статьясындагы $3^4$ өлешенә шундый ук үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә законнарның үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Региональ яисә муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан яисә мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан йөргән өчен түләү алу тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 22 ноябрендәге 1110 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 33 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.